Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
Аккүз авыл җирлегенең Меңнәр авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

05.03.2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең Меңнәр авылындагы 2024 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы гражданнар җыены карарына «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге составына керүче Меңнәр авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» үзгәрешләр кертү турында.

2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлегенең Меңнәр авылындагы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең Меңнәр авылында гражданнар җыенының 2024 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Карарның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 126 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 65 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен __62__ граждан тавыш бирде;

«Каршы " позициясе өчен _3__ граждан тавыш бирде.

«Тыелып калдылар» позициясе өчен __0__ граждан тавыш бирде.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Аккүз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Аккүз авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Г.И.Имамова